СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши, 422594

Красавин ур., 40 нче йорт, Яр Буе Моркваши авылы, 422594

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ | КАРАР

12.11.2025 с. Набережные Моркваши 3-22

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Яр буе Морквашы торак пункт территориясе өлешендә үзара салым кертү һәм аннан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставы нигезендә, 22.11.2013 ел №909 Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән (29.11.2023 ел №1532 редакциясендә)

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Яр буе Морквашы торак пункты территориясе өлешендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 22 ноябренә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Яр буе Морквашы торак пункты территориясе өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 12 000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

- Яр буе Морквашы торак пункты чикләрендә Заречная урамында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Яр буе Морквашы авылы, Красавин урамы, 40 йортта (Башкарма комитет бинасы) 09.00 сәгатьтә уздырырга.

4. Яр буе Морквашы авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И.Х. Гаязов